**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6536**
**03.12.2020**

Яр Чаллы шәһәренең «Виктория» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Виктория» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 3 декабрендәге
6536 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Виктория» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| I. Транспорт чараларын куючы урыны хезмәтләре | | | |
| 1 | Җиңел автомобиль | ай | 900,00 |
| 2 | Микроавтобус | ай | 900,00 |
| 3 | Трактор | ай | 1100,00 |
| 4 | Йөк автомобиле | ай | 1300,00 |
| II. Шугалакның прокат хезмәтләре | | | |
| 1 | 14 яшькә кадәрге балаларга тимераяклар | кеше/1 сәгать | 70,00 |
| 2 | 14 яшьтән зуррак балаларга, зурларга тимераяклар | кеше/1 сәгать | 100,00 |
| 3 | Тимераякларны үткенләү | 1 хезмәт | 100,00 |
| 4 | Шугалакка керү | кеше/1 сәгать | 20,00 |
| III. Командалы спорт төрләре (футбол) буенча чаралар оештыру һәм үткәрү | | | |
| 1 | Футбол кыры | 1 сәгать | 4 000,00 |
| 2 | Футбол кыры 1/2 | 1 сәгать | 2 000,00 |
| 3 | Футбол кыры 1/4 | 1 сәгать | 1 000,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева